Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
«Ульяновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
ГРАЖДАННАРЫ ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлегенең Сосновка торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү һәм аннан файдалану турында

**17 октябрь 2025 ел** **№ 2/5**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлегенең Сосновка торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2026 елда Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлегенең Сосновка авылы территориясендә теркәлгән һәм дәими яшәүче һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәгеләрдән һәм 90 яшьтән өлкәнрәк булган гражданнардан тыш.
2. Алынган чараларны җибәрергә:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (агачларны кисү, юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, Сосновка торак пунктында кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы түләү, ике дәүләт телендә (рус һәм татар телләрендә) урам күрсәткечләрен һәм йорт номерларын ясау һәм урнаштыру, Сосновка торак пунктында аншлаглар урнаштыру һәм буяу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү өчен башка билгеләнештәге җиһазларны ремонтлау (Сосновка торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Сосновка торак пунктындагы су җыю манарасы территориясен, скважиналарны

төзекләндерү, су насосларын сатып алу (ремонтлау), сууткәргеч челтәрләрен ремонтлау);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Сосновка торак пунктында урам-юл челтәрен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, 20-30 мм фракциясендәге вак таш сатып алу).

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге башлыгы С.З. Шәмсетдинов